РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕЛАЩИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЮГАРЫ ЛАШЧЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.08.2026 № 10

Буа муниципаль районының Югары Лашчы авыл җирлеге территориясендә урнашкан каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын урнаштыру урыннары реестрын һәм схемасын раслау турында.

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль законның 13.4 статьясындагы 4 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018елның 31 августындагы 1039номерлы карары белән расланган Каты коммуналь калдыклар туплау урыннарын (мәйданчыкларын) төзеклəндерү һәм аларның реестрын алып бару кагыйдәләре нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Югары Лашчы авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Югары Лашчы авыл җирлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплау урыннары реестрын расларга (1 нче кушымта нигезендә).

2. Каты коммуналь калдыкларны туплау урыны (мәйданчыгы) турында белешмәләрне Буа муниципаль районының Югары Лашчы авыл җирлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны туплау реестрына кертү хакында гариза рәвешен (2 нче кушымта) расларга.

3. Буа муниципаль районының Югары Лашчы авыл җирлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын урнаштыру схемасын (3 нче кушымта) расларга.

4. Буа муниципаль районы Югары Лашчы авыл җирлеге Башкарма комитетының «Буа муниципаль районы Югары Лашчы авыл җирлеге территориясендә урнашкан каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын урнаштыру урыннары реестрын һәм схемасын раслау турында» 2023 елның 09 ноябрендәге 18 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Буа муниципаль районының Югары Лашчы авыл җирлеге территориясендә урнашкан каты коммуналь калдыкларны туплау урыннарының әлеге карар белән расланган реестрын һәм схемасын Буа муниципаль районының Югары Лашчы авыл җирлегенең «Интернет»челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә. шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында http://buinsk.tatarstan.ru. да урнаштырылырга тиеш.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы Югары Лашчы
авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Г.Х.Усманова

Буа муниципаль районының Югары Лашчы
авыл җирлеге башкарма комитетының
2026 елның «05» августындагы
10 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Югары Лашчы авыл җирлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны туплау урыннары реестры

| № | Контейнер мәйданчыгы милекчесе (хуҗасы) (тулы исеме) | Контейнер мәйданчыгы урнашкан урын, мәйданы, өслеге, коймаланганлыгы | Контейнерлар саны (данә) | Контейнерлар күләме ($м^3$) | Мәйданчыкта туплана торган ККК барлыкка килү чыганаклары |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Буа муниципаль районы Югары Лашчы авыл җирлеге башкарма комитеты | Югары Лашчы авылы, Мәктәп урамы, 6 м2, бетон, тимер | 2 | 1,1 | Школьная, Садовая урамнарында яшәүчеләр мәктәп, клуб, ФАП |
| | | Луговая урамы 6 м2, бетон, тимер | 2 | 1,1 | Луговая, Центральная урамнарында яшәчеләр |
| | | Татар Аксуы авылы, Мира урамы 6 м2, бетон, тимер | 2 | 1,1 | Мира Дружба урамнарында яшәүчеләр, клуб, ФАП |
| | | Тутай авылы, Полевая урамы 6 м2, бетон, тимер | 2 | 1,1 | Школьная, Полевая, Речная, Октябрьская урамнарында яшәүчеләр, ФАП кибет |
| | | Тутай авылы Октябрьская урамы, 1 6 м2, бетон, тимер | 2 | 1,1 | Речная, Октябрьская урамнарында яшәүчеләр, клуб |
| | | Чуаш Аксуы, | 2 | | .Шоссейная |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Шоссейная ур.<br>6 м2,<br>бетон,<br>тимер | | 1,1 | урамында яшәүчеләр, ФАП клуб, кибет |
| | | Чуаш Аксуы, Молодежная урамы<br>6 м2,<br>бетон,<br>тимер | 2 | 1,1 | Молодежная урамында яшәүчеләр |

каты коммуналь калдыклар туплану урыннарының (мәйданчыкларының) табылуы турындагы белешмәләр;

каты коммуналь калдыклар туплану урыннарының (мәйданчыкларының) техник характеристикалары турында белешмәләр;

каты коммуналь калдыклар туплау урыннарының (мәйданчыкларының) милекчеләре турында белешмәләр;

каты коммуналь калдыклар тупланган урыннарда (мәйданчыкларда) туплана торган каты коммуналь калдыклар барлыкка килү чыганаклары турында белешмәләр.

Буа муниципаль районының Югары Лашчы
авыл җирлеге башкарма комитетының
2026 елның «05» августындагы
10 номерлы карарына
2 нче кушымта

Каты коммуналь калдыкларны туплау урыны (мәйданчыгы) турында белешмәләрне Буа муниципаль районының Югары Лашчы авыл җирлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны туплау реестрына кертү хакында гариза рәвеше

Буа муниципаль районы Югары Лашчы авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесенә
___________________________
________________

гариза

Каты коммуналь калдыклар туплану урыны (мәйданчыгы) турындагы белешмәләрне Буа муниципаль районының Югары Лашчы авыл җирлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплану урыннары (мәйданчыклары) реестрына кертүегезне сорыйм.

______________________________________________________________________
фамилиясе, исеме һәм (булган очракта) атасының исеме (граждан өчен), исеме (юридик зат өчен),

______________________________________________________________________
мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны (граждан өчен), мөрәҗәгать итүченең булган урыны (юридик зат өчен)

______________________________________________________________________
мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документның реквизитлары (граждан өчен),

______________________________________________________________________
юридик затларның бердәм дәүләт реестрында юридик затны дәүләт теркәве турында язманың дәүләт теркәве номеры

______________________________________________________________________
салым түләүченең идентификация номеры

Каты коммуналь калдыклар тупланган урын (мәйданчык) турында белешмәләр:

| | |
|---|---|
| Каты коммуналь калдыклар туплану урынының (мәйданчыгының) табылуы турындагы белешмәләр | |
| Каты коммуналь калдыклар туплану урынының (мәйданчыгының) техник характеристикалары турында белешмәләр | |
| Каты коммуналь калдыклар туплану урыны (мәйданчыгы) милекчесе турында белешмәләр | |
| Каты коммуналь калдыклар тупланган урында (мәйданчыкта) туплана торган каты коммуналь калдыклар барлыкка килү чыганаклары турында белешмәләр | |

"Шәхси мәгълүматлар турында" 27.07.2006 елгы 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм әлеге гаризаны үтәү максаты белән мин Югары Лашчы авыл җирлеге башкарма комитетына шәхси мәгълүматларымны (Ф.и. о., яшәү адресы, шәхесне раслаучы документлар, өй телефоны/мобиль һәм башкалар) эшкәртүгә ризалык бирәм. Әлеге ризалык Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары һәм Буа муниципаль районы Югары Лашчы авыл җирлеге Башкарма комитетының норматив документлары нигезендә билгеләнә торган тиешле мәгълүматны яисә документларны саклау сроклары беткәнче бирелә.

Кушымта:

- каты коммуналь калдыклар туплану урынын (мәйданчыгын) 1:2000 масштабында урнаштыру схемасы.

Мөрәҗәгать итүче:________________________________________________

Ф.И.А.и. ( гражданин өчен), Ф.И.А.и., вазифасы( юридик зат өчен)

________________________________________________________________

________________________________________________________________

____________________________

(имза)


«_____» _________________20_______ел


М.У.

Буа муниципаль районының Югары Лашчы
авыл җирлеге башкарма комитетының
2026 елның «05»  августындагы
10 номерлы  карарына
3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Югары Лашчы авыл җирлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплау урыннарын (мәйданчыкларын) урнаштыру схемасы.

| № т/б | Җир кишәрлегенең (кварталның) адресы, кадастр номеры, җир кишәрлегенең мәйданы | ККК туплау урыны(мәйданчык) урнашу схемасы, М 1:2000 |
|---|---|---|
| 1 | Югары Лашчы авылы, Школьная, Луговая урамнары 16:14:020101 | ККК туплау урыны(мәйданчык)   |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2 | Татар Аксуы авылы, Мира урамы 16:14:020201 | | <br><br>ККК туплау урыны(мәйданчык) |

| | | |
|---|---|---|
| 3 | Тутай авылы, Полевая урамы Октябрьская урамы 16:14:020301 | <br>ККК туплау урыны(мәйданчык) |

| | | |
|---|---|---|
| 4 | Чуаш Аксуы авылы, Шоссейная, Молодежная урамы 16:14:020401 | <br>ККК туплау урыны(мәйданчык) |